КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 апрель г.Казань № 363

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын исәпкә алу турында» 2019 ел, 20 сентябрь, 856 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын исәпкә алу турында» 2019 ел, 20 сентябрь, 856 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 июль, 592 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзү, реконструкцияләү Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә башкарылган төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестры турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $55^{35}$ статьясының 4 өлеше, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $19^{7}$ статьясының 5 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кararга теркәлгән Төзү, реконструкцияләү Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә башкарылган төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын төзү, реконструкцияләү Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә башкарылган төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрын формалаштыруга һәм алып баруга вәкаләтле орган итеп билгеләргә.»;

3 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төзү, реконструкцияләү Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә башкарылган төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары (алга таба - төгәлләнмәгән төзелеш объектлары) мониторингын үткәрү;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына әлеге Тәртип нигезендә төгәлләнмәгән төзелеш объектлары буенча мәгълүмат бирү.»;

4 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль төгәлләнмәгән төзелеш объектлары мониторингын үткәрү»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына әлеге Тәртип нигезендә муниципаль милектәге төгәлләнмәгән төзелеш объектлары буенча мәгълүмат бирү.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге төгәлләнмәгән төзелеш объектларын исәпкә алу һәм аларның исемлеген алып бару буенча нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзү, реконструкцияләү Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә башкарылган төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Төзү, реконструкцияләү Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә башкарылган төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрын (алга таба - реестр) формалаштыруга һәм алып баруга гомуми таләпләрне, аңа кертелә торган белешмәләрнең составы, мондый белешмәләрне бирү тәртибен билгели»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Төзү, реконструкцияләү Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә башкарылган һәм тәмамланмаган төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $55^{34}$ статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләрдә аның турында белешмәләр реестрга кертелгән көннән алып төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объекты дип таныла.»;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Төзү, реконструкцияләү Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә башкарылган һәм тәмамланмаган төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрга кертелергә тиешле төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектларына карыйлар.»;

3 һәм 4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Реестрны төзү һәм алып бару Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба - вәкаләтле орган) тарафыннан электрон рәвештә башкарыла:

«төзү, реконструкцияләү Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә башкарылган төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары (алга таба - төгәлләнмәгән төзелеш объектлары) турында белешмәләрне кертү;»;

реестрдагы төгәлләнмәгән төзелеш объектлары турындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү;

төгәлләнмәгән төзелеш объектлары турында мәгълүматны реестрдан төшереп калдыру.

4. Төгәлләнмәгән төзелеш объектлары турында белешмәләрне реестрга кертү өчен нигез булып Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (алга таба - җирле үзидарә органнары) тарафыннан әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча төгәлләнмәгән төзелеш объекты турында белешмәләр җибәрү тора, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $55^{34}$ статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләмәнең 51 пункты нигезендә килештерүе булганда.

Реестрдагы төгәлләнмәгән төзелеш объектлары турындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү, төгәлләнмәгән төзелеш объектлары турындагы белешмәләрне реестрдан төшереп калдыру өчен нигез булып Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан белешмәләрне вәкаләтле органына җибәрү тора. Әгәр үзгәрешләр төгәлләнмәгән төзелеш объектларына кертемнәр күләме турындагы белешмәләргә кагылса, реестрда урнашкан төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары турындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы килештерүе булганда, әлеге Тәртипнең $5^1$ пункт нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

5 пунктта:

беренче абзацта «Исемлек» сүзен «Реестр» сүзенә, «Нигезләмә» сүзен «Тәртип» сүзенә, «чагылдырып» сүзен «кертеп» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«хисап чоры ахырына төгәлләнмәгән төзелеш объекты буенча капитал салулар күләме;

төзелеш өчен рөхсәт гамәлдә булу вакыты – төгәлләнмәгән төзелеш объекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $55^{34}$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган нигез буенча реестрга кертелгән очракта;

капиталь төзелеш объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында белешмәләр – тәгәлләнмәгән төзелеш объекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $55^{34}$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында каралган нигез буенча реестрга кертелгән очракта;

капиталь төзелеш объекты урнашкан җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы чыгуы турында белешмәләр, реконструкциясе тәмамланмаган төзелеш яисә төзүче белән төзелгән җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану шартнамәсе турында белешмәләр – тәгәлләнмәгән төзелеш объекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $55^{34}$ статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган нигез буенча реестрга кертелгән очракта;

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6 өлешенең 5 пункты нигезендә мондый объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез булып торучы Россия Федерациясенең җир һәм башка законнарында билгеләнгән чикләүләр барлыкка килү турында белешмәләр – тәгәлләнмәгән төзелеш объекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $55^{34}$ статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган нигез буенча реестрга кертелгән очракта;

мондый төзелешне финанслау, реконструкцияләү Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарылган соңгы елдан башлап өч ел эчендә, мондый төзелеш, реконструкция бюджеттан тыш финанслау чыганаклары исәбеннән башкарылмаган очракта, төзү, реконструкцияләү тәгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектын төзүне, реконструкцияләүне тәгәлләүгә Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет чараларын бюджет законнары нигезендә бүлеп бирүнең булмавы турында белешмәләр – тәгәлләнмәгән төзелеш объекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $55^{34}$ статьясындагы 1 өлешенең 5 пунктында каралган нигез буенча реестрга кертелгән очракта;

капиталь төзелеш объектына карата залог рәвешендә чикләү чараларын арест салу, тыю һәм (яисә) сайлау чараларын капиталь төзелеш объектына карата залог рәвешендә сайлау турында белешмәләр, реконструкцияләү тәмамланмаган төзелеш һәм (яисә) шундый объект урнашкан җир кишәрлеге турында белешмәләр – тәгәлләнмәгән төзелеш объекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $55^{34}$ статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктында каралган нигез буенча реестрга кертелгән очракта;

суд карары үз көченә керү турында, шул исәптән капиталь төзелеш объектын үз белдеге белән төзелгән дип тану хакында белешмәләр, - тәгәлләнмәгән төзелеш объекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $55^{34}$ статьясындагы 1 өлешенең 7 пунктында каралган нигез буенча реестрга кертелгән очракта.»;

түбәндәге эчтәлекле $5^{1}$ пункт өстәргә:

«$5^{1}$. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары буенча мәгълүмат алынганнан соң биш эш көне эчендә тәгәлләнмәгән төзелеш объектларына капитал салулар күләменең туры килү-килмәве турындагы мәгълүматны килештерә һәм вәкаләтле органга килештерү турында белешмәләр җибәрә.»;

6 пунктта «исемлек» сүзен «реестр» сүзенә алмаштырырга.

8 пунктта «исемлеге» сүзен «реестры» сүзенә алмаштырырга, «Нигезләмә» сүзен «Тәртип» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктта «исемлек» сүзен «реестр» сүзенә алмаштырырга.

10 пунктта «Нигезләмә» сүзен «Тәртип» сүзенә алмаштырырга.

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин